ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧӘЧӘКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 8 « 12 » 10. 2020 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советының "Чәчәкле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында" 08.10.2009 ел, № 103 карары белән расланган Чәчәкле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында" ( 24.01.2020 № 120, 13.03.2020 № 125, 16.06.2020 № 131 үзгәрешләр белән )

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге советы
КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советының "Чәчәкле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында" 08.10.2009 ел, № 103 карары белән расланган Чәчәкле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә ( 24.01.2020 № 120, 13.03.2020 № 125, 16.06.2020 № 131 үзгәрешләр белән):
1.1. 10 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.
1.2. Нигезләмәнең 34 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Авыл җирлеге Советының керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турындагы карар проектын җирлек Советына керткәннән соң кабул ителгән норматив хокукый актларының нигезләмәсе агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына.».
2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Чәчәкле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Чәчәкле авыл җирлеге башлыгы: Р.Р. Фәисханов